Республика Татарстан
ЛЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Школьная, д. 1,
с. Ляки, 423366.
Телефон: (85559) 4-66-16
E-mail: Lkn.Sar@tatar.ru

Татарстан Республикасы
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЛӘКЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ

Мәктәп урамы, 1 йорт,
Ләке авылы, 423366.
Телефон: (85559) 4-66-16
E-mail: Lkn.Sar@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2024 ел 21 март** **№ 2**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Дружба торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 17.11.2023 №1, «Дружба торак пунктында гражданнарның 2024 елда үзара салым кертү турында»17.11.2023 № 2 карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Дружба торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар итәм:

1.2024 елның 30 мартында 13.00 сәгатькә Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Дружба авылы, Урман урамы, 15 йорт янында урамда “Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Дружба торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 17.11.2023 №1, «Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Дружба торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салым кертү турында»17.11.2023 №2 гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:
«Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Дружба торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 17.11.2023 №1, «Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Дружба торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салым кертүе турында» 17.11.2023 №2 гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертергә ризамы?
1. Дружба торак пунктында коеларны ремонтлау һәм янәшәсендәге территорияне төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
2. Дружба торак пунктында урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау һәм җиһазларны электр

энергиясе белән тәэмин итү (яктыртуның урам челтәрләрен ремонтлау (лампаларны, таймерларны, энергияне сак тотучы яктырткычларны сатып алу һәм урнаштыру).

«ӘЙЕ «ЮК»

3. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә http://pravo.tatarstan.ru һәм Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында http:// sarmanovo.tatarstan.ru кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге башлыгы Ю.Г.Антонов